**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2014 ел, 31 декабрь № 1098

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2010 ел, 19 ноябрь, 917 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2010 ел, 19 ноябрь, 917 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 12 октябрь, 846 нчы; 2012 ел, 18 июль, 612 нче; 2013 ел, 24 июнь, 435 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендәге һәм 1 нче пунктындагы «башлангыч һөнәр белеме бирү буенча» сүзләрен «квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча» сүзләренә алыштырырга;

преамбуладагы «башлангыч һәм урта һөнәр белеме бирү учреждениеләре» сүзләрен «һөнәр белеме бирү оешмалары» сүзләренә алыштырырга;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына бу карар белән расланган Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программаларын тормышка ашыручы һөнәр белеме бирү оешмаларына җиткерергә һәм аның таләпләре үтәлешен тәэмин итәргә.»;

3 нче пункттагы «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Башлангыч һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты исемендә:

Стандартның 1, 2, 4 – 6, 8 – 14 бүлекләре исемнәрендәге «башлангыч һөнәр белеме бирү буенча» сүзләрен «квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча» сүзләренә алыштырырга;

1 бүлекнең исемендәге «(шул исәптән ташламалы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) файдаланучылар булып төп гомуми белеме, урта гомуми белеме, урта һөнәр белеме, югары белеме булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар, шул исәптән чит илләрдәге ватандашлар тора.»;

1.2 нче пункт, 4.4 нче пунктның дүртенче һәм алтынчы абзацлары, 4.23 нче пункт, 10.1 нче пунктның өченче абзацы, 14.2 нче пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип санарга;

2.1 нче пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон;»;

тугызынчы – уникенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгариф турында» 2013 ел, 22 июль, ТРЗ-68 нче Татарстан Республикасы Законы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү оешмасы турындагы мәгълүматны мәгариф оешмасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм яңарту кагыйдәләрен раслау хакында» 2013 ел, 10 июль, 582 нче карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 15 август, 706 нчы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү эшчәнлеген лицензияләү турында» 2013 ел, 28 октябрь, 966 нчы карары;»;

түбәндәге эчтәлекле унөченче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Белем бирү эшчәнлеген дәүләт аккредитацияләве турында» 2013 ел, 18 ноябрь, 1039 нчы карары;»;

ундүртенче – унҗиденче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Урта һөнәр белеме бирүче белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 14 июнь, 464 нче боерыгы;

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Урта һөнәр белеме һөнәрләре һәм белгечлекләре исемлекләрен раслау турында» 2013 ел, 29 октябрь, 1199 нчы боерыгы;

урта һөнәр белеме бирү буенча федераль дәүләт белем бирү стандартлары;

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Урта һөнәр белеме бирүче белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 23 гыйнвар, 36 нчы боерыгы»;

2.1 нче пунктның егерменче һәм егерме беренче абзацларындагы, 11.2 нче пунктның таблицасындагы «башлангыч һөнәр белеме бирүче мәгариф учреждениесе» сүзләрен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «һөнәр белеме бирү оешмасы» сүзләренә алыштырырга;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

3.1. Белем бирү оешмаларына кабул итү турында гариза биргәндә укырга керүчеләр түбәндәге документларны күрсәтә:

3.1.1. Россия Федерациясе гражданнары:

үзләренең шәхесен, гражданлыгын таныклый торган документларның төп нөсхәсен яки күчермәләрен;

белем һәм (яки) квалификация турындагы документның төп нөсхәсен яки күчермәсен;

4 фотография;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлешендә күздә тотылган очракта, абитуриентны мәҗбүри башлангыч медицина тикшерүе (каравы) турында медицина оешмасы бәяләмәсен.

3.1.2. Чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар, шул исәптән чит илләрдә яшәүче ватандашлар:

укырга керүченең шәхесен таныклый торган документ күчермәсен йә «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 ел, 25 июль, ФЗ-115 нче Федераль законның 10 статьясы нигезендә Россия Федерациясендә чит ил гражданы шәхесен таныклый торган документ;

чит дәүләтнең белем һәм (яки) квалификация турындагы документының төп нөсхәсен (яки аның билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәсен) йә чит дәүләтнең Россия Федерациясендә белем һәм (яки) квалификация турындагы документ дәрәҗәсендә танылa торган белем һәм (яки) квалификация дәрәҗәсе хакындагы документының төп нөсхәсе (яки аның билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәсен), чит илдәге алган белемне тану турындагы таныклык күчермәсен;

чит дәүләтнең белем һәм (яки) квалификация дәрәҗәсе турындагы документының һәм аңа теркәлгән кушымтаның (әгәр соңгысы мондый документ бирелгән дәүләт законнары белән күздә тотылса) билгеләнгән тәртиптә таныкланган рус теленә тәрҗемәсен;

чит илдә яшәүче ватандашның «Чит илләрдәге ватандашларга карата Россия Федерациясе дәүләт сәясәте турында» 1999 ел, 24 май, ФЗ-99 нчы Федераль законның 17 статьясында күздә тотылган төркемнәргә керүен раслый торган документларның яки башка дәлилләрнең күчермәләрен;

4 фотография;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлешендә күздә тотылган очракта, абитуриентны мәҗбүри башлангыч медицина тикшерүе (каравы) турындагы медицина оешмасы бәяләмәсен.

Рус теленә барлык тәрҗемәләр Россия Федерациясендә чит ил гражданы шәхесен таныклый торган документта күрсәтелгән исемгә һәм фамилиягә эшләнергә тиеш.»;

4.1 нче пунктта:

икенче абзацтагы «башлангыч» сүзен «урта» сүзенә алыштырырга;

өченче абзацтагы «башлангыч» сүзен «урта» сүзенә алыштырырга;

4.2 нче һәм 4.3 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Дәүләт хезмәте белем бирү оешмаларының түбәндәге төрләрендә күрсәтелергә мөмкин:

һөнәр белеме бирү оешмалары;

тиешле лицензияләре булса, югары белем бирүче мәгариф оешмалары.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче белем бирү оешмасының (алга таба – белем бирү оешмасы) структур бүлекчә сыйфатында филиаллары, вәкиллекләре, уку-укыту һәм укыту-җитештерү остаханәләре һәм хуҗалыклары, уку-укыту-полигоннары һәм башка структур бүлекчәләре, шул исәптән төп гомуми белем бирү программаларын, һөнәргә өйрәтү программаларын, өстәмә гомуми белем бирү программаларын һәм өстәмә һөнәри программаларны тормышка ашыра торган, булырга мөмкин.

4.3. Белем бирү оешмаларында дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

урта гомуми белем алып, төп гомуми белем базасында квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәр белеме бирү;

урта гомуми белем базасында квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәр белеме бирү;

урта гомуми белем алып, төп гомуми белем базасында квалификация дәрәҗәсе тагын да югарырак (эшче һөнәре буенча разряды тагын да югарырак) булган квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәр белеме бирү;

урта гомуми белем базасында квалификация дәрәҗәсе тагын да югарырак (эшче һөнәре буенча разряды тагын да югарырак) булган квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәр белеме бирү.»;

4.4 нче пунктның өченче абзацындагы, 4.9 нчы пунктның беренче абзацында, 9.5 нче пунктта тиешле килешләрдәге «(кичке)» сүзен төшереп калдырырга;

4.4 нче пунктның беренче абзацында, 4.5 нче пунктта, 4.6 нчы пунктның икенче абзацында, 4.7 нче пунктның икенче абзацында, 4.8, 4.19, 4.25, 5.2, 5.4, 9.2, 11.1 нче пунктларда, 11.2 нче пункт таблицасында тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «башлангыч һөнәр белеме бирү программасы» сүзләрен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программасы» сүзләренә алыштырырга;

4.5, 4.8 нче пунктларда, 4.9 нчы пунктның беренче абзацында, 4.10 нчы пунктның беренче абзацында, 4.20, 4.24, 5.3, 5.6, 7.1 – 7.5 нче пунктларда, 7.7 нче

пунктның беренче һәм икенче абзацларында, 8.1 нче пунктта, 8.2 нче пунктның беренче һәм икенче абзацларында, 8.3 нче пунктның беренче абзацында, 9.1, 9.2, 9.4, 9.6 нчы пунктларда, 9.7 нче пунктның өченче һәм унынчы абзацларында, 10.2 нче пунктның өченче һәм бишенче абзацларында, 13.1 нче пунктта, 14.1 нче пунктның икенче абзацында, 14.2 нче пунктның беренче абзацында тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү учреждениесе» сүзләрен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү оешмасы» сүзләренә алыштырырга;

4.5 нче пункттагы «(тулы)» сүзен төшереп калдырырга;

4.5 нче пунктта, 4.6 нчы пунктның икенче абзацында, 9.7 нче пунктның өченче абзацында, 11.1, 13.2, 14.1 нче пунктларда, 14.2 нче пунктның беренче абзацында тиешле килешләрдәге «башлангыч» сүзен тиешле килешләрдәге «урта» сүзенә алыштырырга;

4.6 нчы пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«һөнәргә өйрәтү программаларын тормышка ашыру.»;

4.7 нче пунктның беренче абзацындагы «Учреждениеләр» сүзен «Оешмалар» сүзенә алыштырырга;

4.9 нчы пунктның беренче абзацындагы «бер ай» сүзеннән соң «, читтән торып уку формасы буенча – иң күбе өч айга» сүзләрен өстәргә, өченче җөмләне төшереп калдырырга;

4.10 нчы пунктның беренче абзацындагы «(производство белеме бирү)» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.11 – 4.13 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.11. Уку төркемендә белем алучылар саны иң күбе 25 кеше тәшкил итә. Белем бирү оешмасы үзенчәлегеннән чыгып, белем бирү оешмасы дәресләрне азрак сандагы белем алучылар төркемнәре һәм аерым укучылар белән, шулай ук төркемне төркемчәләргә бүлеп үткәрергә мөмкин. Дәресләр лекцияләр рәвешендә үткәрелгәндә белем бирү оешмасы укучылар төркемнәрен берләштерергә хокуклы.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучылар саны уку төркемендә 15 кешегә кадәр билгеләнә.

4.12. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларга белем бирү башка укучылар белән бергә дә, аерым сыйныфларда да, төркемнәрдә дә оештырылырга мөмкин.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларны квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерли торган белем бирү программалары буенча өйрәтүне белем бирү оешмасы мондый укучыларның психофизик үсеше үзенчәлекләрен, индивидуаль мөмкинлекләрен һәм сәламәтлекләренең торышын исәпкә алып гамәлгә ашыра.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларга урта һөнәр белеме алу өчен белем бирү оешмалары тарафыннан махсус шартлар тудырылырга тиеш.

4.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланганда студентның уку нагрузкасы максималь күләме, аудиториядәге һәм аудиториядән тыш уку нагрузкасының барлык төрләрен дә кертеп, атнага 54 академик сәгать тәшкил итә. Аудиториядәге мәҗбүри дәресләр һәм практика күләме атнага 36 академик сәгатьтән артмаска тиеш.»;

4.14 нче пунктның беренче абзацында, 5.1, 5.4 нче пунктларда, 6.1 нче пунктның беренче абзацында, 7.3, 8.1, 14.1 нче пунктларда тиешле саннардагы «Белем бирү учреждениесе» сүзләрен тиешле саннардагы «Белем бирү оешмалары» сүзләренә алыштырырга;

4.14 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Укучыларның арадаш аттестациясе процессында имтиханнар саны уку елында – 8 дән, ә зачетлар саны 10 нан артмаска тиеш. Күрсәтелгән санга физик культура һәм факультатив уку курслары, дисциплиналар (модульләр) буенча имтиханнар һәм зачетлар керми. Индивидуаль уку-укыту планы нигезендә укыганда белем алучыларның арадаш аттестациясе процессында имтиханнар һәм зачетлар саны әлеге уку-укыту планы белән билгеләнә.»;

4.15 – 4.17 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.15. Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү буенча белем бирү программаларын үзләштерү мәҗбүри булган йомгаклау аттестациясе белән тәмамлана.

Академик бурычлары булмаган һәм уку-укыту планын яки индивидуаль уку-укыту планын тулы күләмдә үтәгән укучылар – йомгаклау аттестациясен, ә урта һөнәр белеме бирүче белем бирү программалары буенча дәүләт аккредитациясе булган урта һөнәр белеме алганда дәүләт йомгаклау аттестациясен үтә.

4.16. Урта һөнәр белеме бирүче белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен уңышлы үткән затларга урта һөнәр белеме һәм тиешле һөнәр буенча квалификация яки урта һөнәр белеме белгечлеген алуны раслый торган урта һөнәр белеме турында диплом бирелә.

Йомгаклау аттестациясен үтмәгән яки йомгаклау аттестациясендә нәтиҗәләре канәгатьләнмәслек булган затларга, шулай ук квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү буенча белем бирү программасының бер өлешен үзләштергән һәм (яки) белем бирү оешмасыннан чыгарылган затларга белем алу турында яки белем алу чоры хакында белем бирү оешмасы мөстәкыйль билгели торган үрнәктәге белешмә кәгазе бирелә.

4.17. Урта гомуми белемнәре булмаган квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерли торган белем бирү программалары буенча белем алучылар дәүләт йомгаклау аттестациясен үтәргә хокуклы, аның белән урта гомуми белем бирүче белем бирү программаларын үзләштерү тәмамлана һәм аны уңышлы үткәндә аларга урта гомуми белем турында аттестация бирелә. Әлеге белем алучылар дәүләт йомгаклау аттестациясен бушлай үтә.»;

4.19 нчы пункттагы икенче җөмләне төшереп калдырырга;

5.2 нче пункттагы «тормышка ашыра торган белем бирү учреждениесе» сүзләрен «тормышка ашыра торган белем бирү оешмасы» сүзләренә алыштырырга;

5.5 нче пункттагы «Белем бирү учреждениесе» сүзләрен «Белем бирү оешмасы» сүзләренә алыштырырга;

5.6 нчы пункттагы «(производство белеме бирү)» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.2 нче пунктның икенче абзацындагы «расланган» сүзен – «күздә тотылган» сүзләренә, «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш

хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының «Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында (ППБ 01-03)» 2003 ел, 18 июнь, 313 нче боерыгы белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 ел, 25 апрель, 390 нчы карары белән» сүзләренә алыштырырга;

6.2 нче пунктның беренче абзацындагы «дәүләт хезмәте күрсәтүче учреждениене» сүзләрен «белем бирү оешмасын» сүзләренә алыштырырга;

6.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.4. Белем бирү оешмасы үз компетенциясенә кертелгән функцияләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән, уку-укыту планы нигезендә белем бирү программаларын тулы булмаган күләмдә тормышка ашырган, аны тәмамлап чыгучыларның белеме сыйфаты, шулай ук белем алучыларның, белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең тормышы һәм сәламәтлеге өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләгән тәртиптә җавап бирә. Белем алучыларның, ата-аналарның (законлы вәкилләренең), балигъ булмаган белем алучыларның белем алуга хокукын һәм мәгариф турындагы законнар белән күздә тотылган хокукларын һәм ирекләрен бозган яки законсыз чикләгән, белем бирү эшчәнлеген оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне бозган өчен белем бирү оешмасы һәм аның вазыйфаи затлары Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы нигезендә административ җаваплылыкка тартыла.»;

6.5 нче пункттагы «белем бирү учреждениесе буйсына торган» сүзләрен «ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмасы» сүзләренә алыштырырга;

7.5 нче пунктта, 9 бүлек исемендә, 9.6 нчы пунктта, 9.7 нче пунктның алтынчы абзацында тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «учреждение» сүзен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «оешма» сүзенә алыштырырга;

8.2 нче пунктта:

икенче абзацтагы «югары һөнәр белеме» сүзләрен «югары белеме» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:

«каты һәм аеруча каты җинаятьләр өчен бетерелгән яки бетерелмәгән хөкем ителгәнлеге булган»;

8.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.5. Педагог хезмәткәрләргә өстәмә һөнәр белеме бирү Россия Федерациясе законнары нигезендә кимендә өч елга бер тапкыр өстәмә һөнәр белеме бирү оешмаларында, югары белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм башка оешмаларда өйрәнү һәм (яки) стажировка үтү юлы белән оештырыла.»;

9.2 нче пункттагы «башлангыч һөнәр белеме турында дәүләт үрнәгендәге документ бирүгә хокук бирә торган» сүзләрен төшереп калдырырга, «белем бирү учреждениесе» сүзләрен «белем бирү оешмасы» сүзләренә алыштырырга;

9.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.3. Документлар кабул итә башлаганга кадәр кабул итү комиссиясе белем бирү оешмасының рәсми сайтында һәм мәгълүмати стендта түбәндәге мәгълүматны урнаштыра:

1 марттан да соңга калмыйча:

белем бирү оешмасына кабул итү кагыйдәләрен;

түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамәләр буенча укырга кабул итү шартларын;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия нигезендә белем бирү оешмасы укырга кабул итү турында игълан иткән белгечлекләр (һөнәрләр) исемлеген (белем бирү формаларын (көндезге, көндезге-читтән торып, читтән торып) аерып күрсәтеп;

укырга керү өчен кирәкле белем дәрәҗәсенә карата таләпләрне (төп гомуми яки урта гомуми белем);

керү сынауларын үткәрү формалары турында мәгълүмат;

гаризаларны һәм бу Тәртиптә күздә тотылган кирәкле документларны электрон рәвештә кабул итү мөмкинлеге турында мәгълүмат;

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен керү сынауларын үткәрү үзенчәлекләрен;

укырга керүчеләргә мәҗбүри башлангыч медицина тикшерүен (каравын) үтәргә кирәк булу (кирәк булмау) турында мәгълүмат; әлеге тикшерүне үтәргә кирәк булган очракта – табиб-белгечләр исемлеген, лаборатор һәм функциональ тикшеренүләр исемлеген; укырга алырга ярамау турындагы гомуми һәм өстәмә медицина күрсәткечләре исемлеген күрсәтеп;

1 июньнән дә соңга калмыйча:

һәр белгечлек (һөнәр) буенча кабул итү өчен урыннарның барлык санын, шул исәптән белем алуның төрле формалары буенча;

һәр белгечлек (һөнәр) буенча федераль бюджетның, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының, җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән финансланучы урыннар санын, шул исәптән белем алуның төрле формалары буенча;

түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамәләр буенча һәр белгечлек (һөнәр) буенча урыннар санын, шул исәптән белем алуның төрле формалары буенча;

керү сынаулары нәтиҗәләре буенча апелляцияләр бирү һәм аларны карау кагыйдәләрен;

тулай торак булу-булмау һәм тулай торакларда читтән килеп укырга керүчеләр өчен бүлеп бирелә торган урыннар саны турында мәгълүмат;

түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамә үрнәген.»;

9.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.5. Документлар кабул итү чорында кабул итү комиссиясе һәр көн саен белем бирү оешмасының рәсми сайтында һәм кабул итү комиссиясенең мәгълүмати стендында, белем алу формаларын аерып күрсәтеп (көндезге, көндезге-читтән торып, читтән торып), һәр белгечлек (һөнәр) буенча бирелгән гаризалар саны хакында мәгълүмат урнаштыра.

Белем бирү оешмасының кабул итү комиссиясе махсус телефон линияләре һәм белем бирү оешмасының рәсми сайтында белем бирү оешмасына кабул итүгә бәйле

булган мөрәҗәгатьләргә җаваплар бирү өчен бүлек эшчәнлеген тәэмин итә.»;

9.7 нче пунктның беренче абзацындагы «Дәүләт белем бирү учреждениесе» сүзләрен «Дәүләт хезмәте күрсәтүче белем бирү оешмасы» сүзләренә алыштырырга:

11.2 нче пункт таблицасында:

«Башлангыч һөнәр белеме бирү программалары буенча укуларын тәмамлап чыгучыларның гомуми санында башлангыч һөнәр белеме турында диплом алган укуларын тәмамлап чыгучылар өлеше (процент)», «Башлангыч һөнәр белеме бирү программалары буенча бер укучыга федераль исемлеккә кертелгән уку әдәбияты берәмлекләре саны (берәмлек)» юлларындагы «Мәгълүмат чыганагы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урта һөнәр белеме бирүче белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү оешмасы турында мәгълүматлар (Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең 2013 ел, 27 август, 344 нче боерыгы белән расланды)» СПО-1 нче федераль статистика күзәтүе формасы»;

«Башлангыч һөнәр белеме бирү программалары буенча укуларын тәмамлап чыгучыларның гомуми санында башлангыч һөнәр белеме турында диплом алган укуларын тәмамлап чыгучылар өлеше (процент)» юлы буенча «Күрсәткеч (индикатор) исеме, үлчәү берәмлеге» һәм «Хисаплау методикасы» графаларындагы «башлангыч» сүзен «урта» сүзенә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Аттестацияләнергә тиешле вазыйфаларның (штат расписаниесе буенча) гомуми санынннан дәүләт хезмәте күрсәтүче аттестацияләнгән хезмәткәрләр өлеше | процент | $\frac{АР}{ОКД} \times 100$ монда: АР – аттестацияләнгән хезмәткәрләр; ОКД – аттестацияләнергә тиешле вазыйфаларның (штат расписаниесе буенча) гомуми саны | мониторинг | 100 | 3 |
| Тереклек эшчәнлеге иминлеген бозу очраклары булу | берәмлек | учреждениенең матди базасы канәгатьләнерлек булмауга бәйле булган очраклар саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча | 0 | 6 |
| Дәүләт хезмәте күрсәткәндә санитария-гигиена режимын бозулар булу | берәмлек | тикшерүдә тотукүзәтчелек органнары күрсәтмәләрендә билгеләнгән тәртип бозулар саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча | 0 | 8 |
| Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатыннан һәм аннан һәркем файдалана алу дәрәҗәсеннән канәгать булган дәүләт хез- | процент | $\frac{(О к + Од)}{2 \times О} \times 100$ монда: $О_к$ – хезмәт күрсәтүләр сыйфатыннан | дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучылардан сораштырулар нәтиҗәләре буенча | 100 | 7 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| мәте күрсәтүдән файдаланучылар өлеше | | канәгать булган сораштырылучылар саны, $О_д$ – хезмәт күрсәтүдән һәркем файдалана алу дәрәҗәсеннән канәгать булган сораштырылучылар саны, О – сораштырылучыларның гомуми саны | | | |
| Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларның нигезле шикаятьләре өлеше | процент | $\frac{Жо}{Ж} \times 100$, монда: Жо – дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларның хисап чорында кергән нигезле шикаятьләре саны; Ж – дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучыларның хисап чорында кергән шикаятьләре гомуми саны | дәүләт хезмәтләре күрсәтүдән файдаланучылар шикаятьләрен анализлау һәм алар буенча күрелгән чаралар турында мәгълүматлар | 0 | 8»; |

12.1 – 12.5 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.1. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү тәртипләрен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) белем бирү оешмасына кәгазь чыганакта язма рәвештә йә электрон рәвештә бирелә. Белем бирү оешмасы җитәкчесе кабул иткән карарларга карата шикаять югарыдагы органга (булган очракта) бирелә йә ул булмаганда турыдан-туры белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан карала.

12.2. Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, белем бирү оешмасының рәсми сайтыннан, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча бердәм порталдан йә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча төбәк порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнарда билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Шикаять аны теркәгән көннән унбиш көн эчендә, ә белем бирү оешмасы, белем бирү оешмасының вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларны кабул итүдән йә җибәрелгән хаталарны һәм төгәлсезлекләрне төзәтүдән яки мондый төзәтмәләрне кертү буенча билгеләнгән вакыт бозылуга карата шикаять бирелгән очракта, аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә баш тартуга карата шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат тарафыннан каралырга тиеш.

12.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча белем бирү оешмасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында язма рәвештә яки гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә нигезле җавап җибәрә.»;

Стандартка түбәндәге эчтәлекле 12.6 нчы пункт өстәргә:

«12.6 Граждан (аның законлы вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле булган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.»;

13.2 нче пункттагы «булган белем бирү учреждениесенә» сүзләрен «булган белем бирү оешмасына» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2014\1098.doc